ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ГОРОДА МАМАДЫШ
МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.М.Джалиля, д.23/33, г. Мамадыш,
Республика Татарстан, 422190

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫНЫҢ МАМАДЫШ
ШӘҺӘРЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
М.Җәлил ур, 23/33 й., Мамадыш ш.,
Татарстан Республикасы, 422190

Тел.: (85563) 3-31-55, факс 3-17-51, e-mail: Gorod.Mam@tatar.ru, www.mamadysh..tatarstan.ru

**Постановление** **Карар**

№ 30 « 27 » май 2017 ел

2017 елда Нократ елгасы ярында
су коену сезоны ачылуга шәһәр
халкының күпләп ял итү урынын
әзерләү турында.

«Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан су объектларында кешеләрнең тормышын саклау кагыйдәләрен раслау турында» 2009 елның 23 апрелендәге ТР МК №256 карары нигезендә, Мамадыш муниципаль районы башкарма комитеты турында Нигезләмәгә таянып, Мамадыш муниципаль район мамадыш шәһәре Башкарма комитеты карар бирә:

1. 2017 елның 10 июненә кадәр Мамадыш муниципаль районының «Шәһәр хуҗалыгы» муниципаль унитар предприятиесенә Пузанка тавы янындагы чишмәнең уң ярында шәһәрлеләрнең күпләп ял итү урынын су коену сезонына кадәр су төшкәнче, ягъни Нократ елгасы үз юлына кереп беткәнче , әзерләргә тәкъдим итәргә.

1.1. Пляж территориясен чүп-чардан чистарту эшләрен башкарырга.

1.2. Киенү өчен 2 кабина әзерләргә һәм урнаштырырга.

1.3. Су үткәрми торган чокырлар белән су кырыеннан 50 метрдан да ким булмаган һәм су коену урыныннан 200 метрдан да артык булмаган ераклыкта санитар таләпләргә ярашлы рәвештә(ирләр һәм хатын-кызлар) бәдрәфләрен ясарга һәм урнаштырырга.

1.4. 5 күләгәле түбә ясарга һәм урнаштырырга.

1.5. Санитар таләпләр нигезендә каты өслекле контейнерны һәм чүп-чар өчен 6 чүп савыты урнаштырырга.

1.6. Тыю билгеләрен куярга:

- Пузанка тавы янындагы чишмә янында Нократ елгасының уң як ярында "Автотранспорт чаралары юу тыела"
- Шәһәр халкының күпләп ял итү урыныннан 50 метр ераклыкта - «Керү тыела».

2. Түбәндәгеләр рөхсәт ителми:

- Тормыш һәм сәламәтлек өчен куркыныч булган урыннарда су коену тыела, мондый урыннарда тиешле билгеләр куелырга тиеш.

- Автотранспорт чараларының Нократ елгасында кешеләрнең күпләп ял итү урыннарына керүе рөхсәт ителми.

3. ТР Гадәттән тыш хәлләр министрлыгы каршындагы Эзләү-коткару хезмәтенең 5 нче Зональ эзләү-коткару отрядына төзелгән килешү нигезендә елга төбен чистартырга һәм су коену урынына кисәтү билгеләрен (буйлар)куюны тәкъдим итәргә.
4. Мамадыш районы буенча Гадәттән тыш хәлләр министрлыгы идарәсенә һәм Мамадыш муниципаль районының «Шәһәр хуҗалыгы» муниципаль унитар предприятиесенә түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:
4.1. вакытлыча коткару постлары оештырырга.
4.2. Ашыгыч җавап бирү өчен оператив төркемнәрне даими әзерлектә тотырга.
5. «Мамадыш үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенә түбәндәгеләрне эшләргә:
5.1. Медицина постлары эшчәнлеге.
5.2. Халык арасында беренче медицина ярдәме күрсәтү буенча аңлату эшләре алып бару.
6. Россия Эчке эшләр министрлыгының Мамадыш муниципаль районы бүлегенә массакүләм су коену урыннарында даими контрольне тәэмин итәргә, Мамадыш муниципаль районы буенча гадәттән тыш хәлләр министрлыгы идарәсе белән уртак рейдлар оештырырга тәкъдим итәргә.
7. ТР буенча Роспотребнадзор идарәсенә Мамадыш районында һәм Мамадыш шәһәрендә суның торышын контрольдә тотарга һәм Мамадыш шәһәренең Башкарма комитетына суның санитар-гигиена нормаларына һәм кагыйдәләренә туры килүе турында мәгълүмат бирергә тәкъдим итәргә.
8. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Мамадыш шәһәре
Башкарма комитеты
җитәкчесе Р.М.Гарипов